СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.03.2023 г.Зеленодольск № 271

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2007 елның 30 июлендәге 210 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мактаулы гражданы» исеме турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2007 елның 30 июлендәге 210 номерлы карары белән расланган (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2008 елның 22 августындагы 373 номерлы, 2008 елның 20 октябрендәге 386 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мактаулы гражданы» исеме турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы Урынбасары мәгълүматын тыңлап, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2007 елның 30 июлендәге 210 номерлы карары белән расланган (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2008 елның 22 августындагы 373 номерлы, 2008 елның 20 октябрендәге 386 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләре белән), «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы мактаулы гражданы» исеме турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 1.4 нче пунктта «егерме биш мең сум» сүзләрен «утыз мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 3.2 нче пунктының бишенче абзацында «өч мең сум» сүзләрен «биш мең сум» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 3.2 нче пунктның алтынчы абзацында «егерме биш мең сум» сүзләрен «утыз мең сум» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат Порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, совет рәисе** **М. П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ИНН 1648017831 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ